КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 сентябрь г.Казань № 1147

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 ноябрь, 1266 нчы карары белән расланган Максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган, 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының бюджетара трансфертларны күчерү вәкаләтләре Татарстан Республикасы бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан алар кабул иткән карарлар нигезендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2022 ел, 29 ноябрь, 1266 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 апрель, 539 нчы; 2023 ел, 14 июль, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан

Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган, 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының бюджетара трансфертларны күчерү вәкаләтләре Татарстан Республикасы бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан алар кабул иткән карарлар нигезендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (аларга үзгәреш кертү, өстәү) буенча дәүләт вәкаләтләрен финанслар белән тәэмин итү өчен бюджетларга субвенцияләр» юлының 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлекләрнең үтәтү-боеру характерындагы органнарына тапшырылган Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (аларга үзгәреш кертү) буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр»;

түбәндәге юлдан соң:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт һәм хосусый (муниципаль-хосусый) партнерлык яисә концессия килешүләре турында килешүләр нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә) чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәрендә «СоТворение» музыка һәм яңа медиа фестиваленең вакыйгалы чарасына ярдәм күрсәтү һәм аны этәрү өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин